ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $2^1$ статьяның 2 өлешендәге 6 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 5 статьяның 11 өлешендә «9 һәм 16 статьяларында» сүзләрен «9, 15 һәм 16 статьяларында» сүзләренә алмаштырырга;

3) 7 статьяның 13 өлешендә «9 һәм 21 статьяларында» сүзләрен «9, 20 һәм 21 статьяларында» сүзләренә алмаштырырга;

4) 10 статьяда:

а) 13 өлештә «яисә рекреация билгеләнешендәге зоналарны ачыклау» сүзләрен «, рекреация билгеләнешендәге зоналарны ачыклау яисә торак пункт чикләренең җир кишәрлекләре чикләре белән кисешүен бетерү» сүзләренә алмаштырырга;

б) 15 өлештә «9 һәм 25 статьялары» сүзләрен «9, 24 һәм 25 статьялары» сүзләренә алмаштырырга;

5) $10^1$ статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Бердәм документ әлеге статьяда һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $28^1$ статьясында каралган таләпләр нигезендә ике һәм аннан артыграк җирлек, һәм (яисә) шәһәр округы, һәм (яисә) аларның составына керүче аерым торак пунктлар территорияләренә карата әзерләнергә һәм расланырга мөмкин.»;

б) 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әлеге статьяның $1^1$ өлешендә каралган бердәм документ Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.»;

6) 18 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктының «а» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктының «а» пунктчасы 2024 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

3. Территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында карар, мондый документларга үзгәрешләр кертү турында карар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы $8^1$ һәм 18 өлешләре («Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 10 июлендәге 305-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) редакциясендә) нигезендә территорияне планлаштыру документларын әзерләүнең һәм раслауның Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртипләре үз көченә кергән көнгә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителгән булса, мондый карар нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларын, мондый карар нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларына үзгәрешләрне раслау Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы $8^1$ һәм 19 өлешләре (Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган редакциядә), «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясындагы 2 өлешенең 6 пункты һәм 18 статьясы (әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган редакциядә) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 100-ТРЗ